**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЕТЮШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
422370 г.Тетюши, ул. Малкина, 39

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӘТЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422370 Тәтеш шәһәре, Малкин ур., 39

тел. (84373) 2-50-02, 2-53-33, факс 2-62-48, e-mail: tatesh@tatar.ru
ОКПО 78702080, ОГРН 1061672000026, ИНН/КПП 1638004985/163801001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

06.02.2025 № 68

**Тәтеш муниципаль районында салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләүне уздыру тәртибен раслау турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 1743 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә гомуми таләпләр турында " 2019 елның 22 июнендәге 796 номерлы карары нигезендә Тәтеш муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ::

1. Тәтеш муниципаль районында салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләүне уздыру тәртибен расларга.

2. Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә 1 апрельгә кадәр Тәтеш муниципаль районы Башкарма комитетына хисап елындагы һәм хисап елына кадәрге елдагы һәр салым чыгымы буенча белешмәләр җибәрүне тәкъдим итәргә:

- ташламалардан файдаланган түләүчеләр саны турында;
- Тәтеш муниципаль районы бюджетының төшеп кала торган керемнәре суммалары турында;
- салым чыгымнарын стимуллаштыручы һәр салым чыгымы буенча Тәтеш муниципаль районы бюджетына түләүчеләр тарафыннан декларацияләнгән салым күләмнәре турында.

3. Әлеге карарны Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Тәтеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары М.Д. Храменковага йөкләргә.

**Җитәкче** **А.А. Гасыймов**